КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 26 август г.Казань № 594

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау тәртибе турында» 2009 ел, 31 декабрь, 933 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау тәртибе турында» 2009 ел, 31 декабрь, 933 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 7 июнь, 438 нче; 2010 ел, 24 август, 676 нчы; 2010 ел, 22 декабрь, 1094 нче; 2011 ел, 25 гыйнвар, 41 нче; 2012 ел, 24 октябрь, 901 нче, 2013 ел, 28 март, 211 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Гражданнар сәламәтлеген саклау турында» 1998 ел, 18 июнь, 1659 нчы Татарстан Республикасы Законының 22 статьясы» сүзләрен «Татарстан Республикасында гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясы» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «әлеге карарга 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 һәм 6 пунктларда тиешле килешләрдәге «сәламәтлек саклау учреждениеләре» сүзләрен тиешле килешләрдәге «медицина оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктта «төбәк регистры мәгълүматларын кабул итү-тапшыру актына кул куеп» сүзләрен «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының вәкаләтле хезмәткәренең электрон имзасы белән кул куеп» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктта «түләүсез тулы кыйммәтле туклану алган өч яшькә кадәрге балалар турында мәгълүматларны итү-тапшыру актына кул куеп» сүзләрен «Татарстан Республикасының мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесенең вәкаләтле хезмәткәренең электрон имзасы белән кул куеп» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктта «медицина учреждениеләрендә» сүзләрен «медицина оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $11^1$ пункт өстәргә:

«$11^1$. Табиблар рецептлары буенча өч яшькә кадәрге балаларга махсус сөт продуктларын һәм катнашмаларын (алга таба – тулы кыйммәтле туклану) түләүсез бирүне гамәлгә ашыручы медицина оешмалары мәгълүматлар базасы рәвешендә «Татарстан Республикасының мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесенә тапшыру өчен балаларны тулы кыйммәтле туклану белән түләүсез тәэмин итү буенча күрсәтелгән хезмәтләр өчен деперсонификацияләнгән счет-реестрны (алга таба – счет-реестр) фоормалаштыра.»;

әлеге карарга 1 нче һәм 2 нче кушымталар үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карарга 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2009 ел, 31 декабрь, 933 нче
карарына 3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 26 август, 594 нче
карары редакциясендә)

Туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин ителүгә хокуклы өч яшькә кадәрге балаларның төбәк регистры мәгълүматлары структурасы һәм форматы

| Т/с | Кырның исеме | Кырны билгеләү | Кырның төре һәм күләме | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Баланың коды | CODE_CHILD | NUM(12) | Ташлама бирелүченең уникаль коды<*> |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 2. | Фамилиясе | SURNAME | CHAR(30) | |
| 3. | Исеме | FIRSTNAME | CHAR(30) | |
| 4. | Атасының исеме | PATRONYMIC | CHAR(30) | |
| 5. | Туган көне, ае, елы | DOB | DATE | |
| 6. | Җенесе | SEX | CHAR(1) | Рөхсәт ителә торган мәгънә: И.а., Х.-к. |
| 7. | Туу турындагы таныклыкның тибы | SERT_TYPE | NUM(2) | 1 – Россиянеке;<br>2 – чит илнек |
| 8. | Бала туу турындагы таныклык сериясе | SERTIF_SER | CHAR(30) | Маска R-ББ<**> |
| 9. | Бала туу турындагы таныклыкның номеры | SERTIF_NO | CHAR(10) | Маска 999999 <**> |
| 10. | ОКАТО буенча адрес коды | CODE_ATO | CHAR(11) | |
| 11. | Торак пункт | LOCALITY | CHAR(50) | |
| 12. | Урам | STREET | CHAR(30) | |
| 13. | Йорт | HOUSE | NUM(8) | |
| 14. | Йорт литерасы | HOUSE_LET | CHAR(1) | |
| 15. | Корпусы | BLOCK | NUM(2) | |
| 16. | Фатиры | FLAT | NUM(7) | |
| 17. | Фатир литерасы | FLAT_LET | CHAR(1) | |
| 18. | Номер комнаты | LITKVAR | CHAR(3) | |
| 19. | Бүлмә номеры | D_BEG_CAT1 | DATE | |
| 20. | 1 нче категорияне бирү датасы | D_BEG_CAT3 | DATE | |
| 21. | 2 нче категорияне бирү датасы | D_BEG_CAT4 | DATE | |
| 22. | 1 нче категорияне кире алу датасы | D_END_CAT1 | DATE | |
| 23. | 2 нче категорияне кире алу датасы | D_END_CAT3 | DATE | |
| 24. | 4 нче категорияне кире | D_END_CAT4 | DATE | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | алу датасы 4 | | | |

<**> Туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин ителүгә хокуклы өч яшькә кадәрге балаларның төбәк регистрында ташлама бирелүче коды Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан формалаштырыла.

<**> Туу турындагы Россия таныклыгының номеры һәм сериясе маскасы форматы түбәндәге кагыйдәләргә җавап бирергә тиеш:

R – бер «R» символы урынына латин клавиатурасының югары регистрында җыелган «I», «V», «X», «L», «C» символлары белән бирелгән тулысы белән рим саны урнаштырыла;

Б – рус алфавитындагы теләсә кайсы баш хәреф;

9 – ун урынлы теләсә кайсы сан (мәҗбүри).»;

әлеге карар белән расланган Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү тәртибен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2009 ел, 31 декабрь, 933 нче
карарына 3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 26 август, 594 нче
карары редакциясендә)

Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү тәртибе

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасында өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары (алга таба – тулы кыйммәтле туклану) белән түләүсез тәэмин итү механизмын билгели.

2. Табиблар рецептлары буенча тулы кыйммәтле туклану белән түләүсез нигездә Татарстан Республикасында даими яшәүче, республиканың сәламәтлек саклау учреждениеләрендә яшәү урыны буенча амбулатор исәптә торучы, ясалма һәм катнаш тукландырыла торган түбәндәге балалар тәэмин ителә:

җан башына исәпләнгән уртача кереме Татарстан Республикасы территориясендә җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган гаиләләрнең өч яшькә кадәрге балалары. Гаиләдә күрсәтелгән яшьтәге ике һәм аннан да күбрәк бала булса, бу хокукка һәр бала да ия була;

бу Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада күрсәтелгән хроник авырулы өч яшькә кадәрге балалар. Гаиләдә күрсәтелгән яшьтәге ике һәм аннан да күбрәк бала булса, бу хокукка һәр бала да ия була;

ВИЧ-йоктырылган аналардан туган һәм ВИЧ-инфекцияле өч яшькә кадәрге балалар (МКБ10 коды – R75; B20). Гаиләдә күрсәтелгән яшьтәге ике һәм аннан да күбрәк бала булса, бу хокукка һәр бала да ия була.

3. Тулы кыйммәтле туклану белән берничә нигез буенча түләүсез тәэмин ителү хокукы булганда мондый тәэмин итү бары тик бер нигез буенча гына гамәлгә ашырыла.

4. Балаларны тулы кыйммәтле туклану белән түләүсез тәэмин итү хокукына ата-ананың (законлы вәкилләрнең) берсе генә ия була.

5. Тулы кыйммәтле туклану белән түләүсез тәэмин итү бу Тәртипкә теркәлгән 2 нче һәм 3 нче кушымталарда китерелгән нормалар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Баланың 6 яки 12 ай яшенә җиткән көненнән алып тулы кыйммәтле туклану белән тәэмин итү тиешле яшь категориясе өчен билгеләнгән нормалар нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән категорияләргә кертелмәгән балалар тулы кыйммәтле туклану белән гражданнарның шәхси акчасы исәбеннән тәэмин ителергә мөмкин.

7. Тулы кыйммәтле туклану белән түләүсез тәэмин итү турындагы карарны бала яшәгән урын буенча медицина оешмасының участок табибы-педиатры кабул итә.

8. Тулы кыйммәтле туклану белән түләүсез тәэмин итү турындагы карар Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Дару чараларын, медицина билгеләнешендәге әйберләрне һәм махсуслаштырылган дәвалану продуктларын билгеләү һәм язып бирү тәртибе турында» 2007 ел, 12 февраль, 110 нчы карары белән расланган 148-1/у-06 формасы буенча рецепт белән рәсмиләштерелә.

9. Тулы кыйммәтле туклану белән түләүсез тәэмин итүгә рецепт бирү өчен түбәндәгеләр нигез булып санала:

баланы бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән категорияләргә кертү;

җан башына исәпләнгән уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның җан башына яшәү минимумының билгеләнгән күләменнән кимрәк булган гаиләләр балаларының төбәк регистрындагы бала турында мәгълүмат булу яки «Республика матди ярдәм үзәге (компенсация түләүләре)» дәүләт казна учреждениесе бүлегеннән гаиләнең җан башына уртача кереме халыкның җан башына яшәү минимумының Татарстан Республикасында билгеләнгән күләменнән артмаганлыкны раслый торган белешмә булу.

10. Тулы кыйммәтле туклану белән түләүсез тәэмин итүгә рецептлар медицина оешмасының участок табибы-педиатры тарафыннан айга бер тапкыр ике нөсхәдә язып бирелә.

Рецептның беренче нөсхәсе – атага яки анага (законлы вәкилгә) бирелә, рецептның икенче нөсхәсе исәпкә алу һәм саклау максатлары өчен амбулатория-поликлиника учреждениесендә калдырыла.

Рецептлар «Түләүсез» дигән штамп сугылган рецептларны теркәү журналында теркәлә, рецептларны саклау өчен «Түләүсез» дигән штамп сугылган папкада саклана.

Баланың үсеш тарихында (112 нче форма, СССР Сәламәтлек саклау министрлыгының 1980 ел, 4 октябрь, 1030 нчы боерыгы белән расланган) рецепт бирү турында тиешле язу языла.

11. Тулы кыйммәтле туклану белән тәэмин итү рецептларында баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, рецепт язылган көнгә яше, йорт адресы, тулы кыйммәтле туклану белән тәэмин итү өчен күрсәткечләр (авыруның диагнозын күрсәтеп, социаль яки медицина күрсәткечләре), балалар туклануы өчен продуктның исеме һәм аның көнлек микъдары, рецептның гамәлдә булу вакыты күрсәтелә.

12. Тулы кыйммәтле туклануны җибәрү сөт өләшү пунктлары, медицина оешмалары каршындагы тулы кыйммәтле туклану пунктлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

13. Тулы кыйммәтле туклануны җибәрү турындагы мәгълүматлар сөт өләшү пунктлар, медицина оешмалары каршындагы тулы кыйммәтле туклану пунктлары тарафыннан әзер продукция җибәрү журналында теркәлә.

Өч көн эчендә әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән категорияләргә кертелгән баланың ата-анасы (законлы вәкиле) алырга килмәгән махсус сөт туклану продуктлары һәм катнашмалары таләп ителмәгән тулы кыйммәтле туклану (алга таба – таләп ителмәгән тулы кыйммәтле туклану) дип санала.

14. Сөт өләшү пунктлары, медицина оешмалары каршындагы тулы кыйммәтле туклану пунктлары тулы кыйммәтле туклану китерелгән беренче көннән соң өч көн эчендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы раслаган форма буенча медицина оешмасына таләп ителмәгән тулы кыйммәтле туклану турында мәгълүмат җибәрә.

15. Медицина оешмасы таләп ителмәгән тулы кыйммәтле туклануны бер көн эчендә әлеге Тәртип һәм бер көнгә бер балага тулы кыйммәтле туклану бирү ноормалары нигезендә әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән категорияләргә керүче беренче булып теркәлгән балалар файдасына яңадан бүлә һәм сөт өләшү пунктларына, медицина оешмалары каршындагы тулы кыйммәтле туклану пунктларына җибәрә.

Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән категорияләргә керүче, тулы кыйммәтле туклану китерелгән беренче көннән соң өч көн эчендә ата-анасы (законлы вәкиле) тулы кыйммәтле туклануны алырга килмәгән баланы тулы кыйммәтле туклану белән тәэмин итү хокукы тулы кыйммәтле туклану бирелмәгә көннәрне исәпкә алмыйча, ташламалы чорның ахырына кадәр саклана.

Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән категорияләргә керүче баланы таләп ителмәгән тулы кыйммәтле туклану исәбеннән тәэмин итү агымдагы айда медицина оешмаларына килә торган тулы кыйммәтле туклану күләме чикләрендә башкарыла.

16. Сөт өләшү пунктлары, медицина оешмалары каршындагы тулы кыйммәтле туклану пунктлары ай саен медицина оешмаларына алучылардан чыгып тулы кыйммәтле тукылануны тарату турында хисап җибәрә.

17. Тулы кыйммәтле туклану белән түләүсез тәэмин итү түбәндәге очракларда туктатыла:

бала әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы икенче, өченче абзацларда күрсәтелгән категорияләрдән чыгарылган айдан соң килүче айның беренче көненнән;

тулы кыйммәтле туклану алуга тәэсир итә торган шартлар барлыкка килгән көннән (күченеп китү, балага ике яки өч яшь тулган, бала үлгән).

18. Тулы кыйммәтле туклану белән түләүсез тәэмин итү чыгымнарын финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.»;

Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү тәртибенә 1 нче кушымта

«Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү тәртибенә 1 нче кушымта

Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү рәвешендә социаль ярдәм чарасы күрсәтелә торган авырулар исемлеге

| Авыруның исеме | МКБ 10 буенча авыру коды |
|---|---|
| Анемия | D50.8, D50.9 |
| Аксым-энергия җитешмәү | E43, E44.0, E45, E46»; |

Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү тәртибенә 2 нче кушымта

«Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү тәртибенә 2 нче кушымта

Җан башына исәпләнгән уртача кереме Татарстан Республикасы территориясендә җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган гаиләләрнең өч яшькә кадәрге балаларны һәм табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү рәвешендә социаль ярдәм чарасы күрсәтелә торган авырулар исемлегенә кертелгән өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү
нормалары

| Продукт исеме | Бер көнгә бер балага бирү нормасы | | |
|---|---|---|---|
| | 0 – 6 ай | 6 – 12 ай | 1 – 3 яшь |
| Сыек адаптацияләнгән сөт катнашмасы, мл | 200,0 | 200,0 | - |
| Сөт, мл | - | 200,0 | 200,0 |
| Кефир һәм башка әчетелгән сөт продуктлары, мл | - | 100,0 | 200,0 |
| Эремчек, г | - | 30,0 | 40,0»; |

Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү тәртибенә 3 нче кушымта

«Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү тәртибенә 3 нче кушымта

Табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү рәвешендә социаль ярдәм чарасы күрсәтелә торган ВИЧ-йоктырылган аналардан туган һәм ВИЧ-инфекцияле өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү нормалары

| Продукт исеме | Бер көнгә бер балага бирү нормасы | | |
|---|---|---|---|
| | 0 – 6 ай | 6 – 12 ай | 1 – 3 яшь |
| Сыек адаптацияләнгән сөт катнашмасы, мл | 400,0 | 200,0 | - |
| Сөт, мл | - | 200,0 | 200,0 |
| Кефир һәм башка әчетелгән сөт продуктлары, мл | - | 100,0 | 200,0 |
| Эремчек, г | - | 30,0 | 40,0»; |

әлеге карар белән расланган Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү рәвешендә социаль ярдәм чарасы күрсәтү кысаларында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы арасында мәгълүмат алмашу тәртибендә:

2 пунктның икенче абзацында «җан башына яшәү минимумының билгеләнгән күләменнән кимрәк булган гаиләләрдә яшәүче өч яшькәчә балаларының төбәк регистрындагы мәгълүматларны бирү-алу актын имзалап» сүзләрен «вәкаләтле хезмәткәрнең электрон имзасы белән имзалау» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктның беренче абзацында «2011 елга» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктның икенче абзацында «түләүсез тулы кыйммәтле туклану алган өч яшькәчә балалар турында мәгълүматларны бирү-алу актын имзалап» сүзләрен «вәкаләтле хезмәткәрнең электрон имзасы белән имзалау» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 2 нче һәм 4 нче кушымталарны үз көчен югалткан дип танырга;

Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итүне оештыру буенча «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының диспетчер үзәге» дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү тәртибен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2009 ел, 31 декабрь, 933 нче
карары белән расланды

Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итүне оештыру буенча «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының диспетчер үзәге» дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итүне оештыру буенча «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының диспетчер үзәге» дәүләт автоном учреждениесе (алга ттаба – Диспетчер үзәге) тарафыннан дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү механизмын билгели.

2. Диспетчер үзәгенә субсидия әлеге максатларга тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет йөкләмәләренең бюджет ассигнованиеләре һәм лимитлары кысаларында бирелә.

3. Диспетчер үзәгенә субсидия күләме дәүләт хезмәте күрсәтү буенча дәүләт йөкләмәсе нигезендә һәм өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итүгә норматив чыгымнар белән, шулай ук ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели торган консультацион һәм методик хезмәтләр күрсәтү буенча дәүләт эшләренә норматив чыгымнар белән билгеләнә.

4. Диспетчер үзәге Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы билгеләгән дәүләт йөкләмәсен үтәгәндә субсидияләр күләме киметелә алмый.

5. Диспетчер үзәге йөкләмәне гамәлдә каралганнан ким күләмдә яки йөкләмәдә билгеләнгән сыйфатка яки тиешле хезмәтк үкрсәтүләргә таләпләргә туры килми торган итеп үтәгәндә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы субсидия күләме киметүне һәм (яки) автоном учреждениегә бирелгән субсидияне гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә өлешчә (тулысынча) кире кайтартуны тәэмин итә.

6. Ай саен, хисап аеннан соң килүче айның 15енә кадәр Диспетчер үзәге Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итүне оештыру буенча дәүләт йөкләмәсе үтәлеше хакында хисап тапшыра.

7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ай саен, хисап аеннан соң килүче айның 20сеннән соңга калмый Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә

һәм формада  өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итүне оештыруга юнәлтелгән Татарстан Республикасы бюджета акчасын тоту турында хисап тапшыра.

8. Диспетчер үзәге тарафыннан дәүләт йөкләмәсе үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков